# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«30» июль 2021 ел Яр Чаллы № 2186

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 декабрендәге «2015-2020 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 7132 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге «2015-2024 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау хакында» 512 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 3 октябрендәге 741, 2016 елның 20 февралендәге 104, 2016 елның 26 маендагы 354, 2016 елның 9 ноябрендәге 832, 2017 елның 26 маендагы 311, 2018 елның 26 мартындагы 174, 2018 елның 10 сентябрендәге 763, 2019 елның 17 июнендәге 495, 2019 елның 16 сентябрендәге 837, 2019 елның 25 декабрендәге 1201, 2020 елның 1 июнендәге 451, 2020 елның 9 сентябрендәге 814, 2021 елның 25 мартындагы 169 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 декабрендәге «2015-2020 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 7132 номерлы карарына (барлык кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемендә, 1 пунктта «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алыштырырга.

1.2. «2015-2020 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы паспортында:

- исемендә «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алыштырырга;
- Программа паспортында:

- «Программа исеме» юлында «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алыштырырга;

- «Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары» юлында «2015-2023» саннарын «2015- 2024» саннарына алыштырырга;

- «Программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты средстволары хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме 290000 сум тәшкил итә | |
| | 2015 | 20000 |
| | 2016 | 20000 |
| | 2017 | 20000 |
| | 2018 | 20000 |
| | 2019 | 20000 |
| | 2020 | 20000 |
| | 2021 | 20000 |
| | 2022 | 40000 |
| | 2023 | 50000 |
| | 2024 | 60000 |
| | Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразланган характерда һәм аңа, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; | |

- «Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлының беренче абзацында «2023 ел ахырына» сүзләрен «2024 ел ахырына» сүзләренә алыштырырга;

- Программаның II бүлегендә:

- унберенче абзацта «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алыштырырга;

- Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

2015-2024 елларда Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты средстволары хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме 290000 сум тәшкил итә, шул исәптән:

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты средстволары күләме |
|---|---|
| 2015 | 20000 |
| 2016 | 20000 |
| 2017 | 20000 |
| 2018 | 20000 |
| 2019 | 20000 |

| | |
|---|---|
| 2020 | 20000 |
| 2021 | 20000 |
| 2022 | 40000 |
| 2023 | 50000 |
| 2024 | 60000 |

Программаны финанслау күләмнәре фаразланган характерда һәм аңа, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Моннан тыш, Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен, чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчалардан файдалану күздә тотыла»;

- Программаның V бүлегендә «2023 елга» сүзләрен «2024 елга» сүзләренә алыштырырга;

Программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин